


Кадошкино районы Насакан Потьма авылында барлыгы 25 кеше яши, аларнын 11-лаеклы ялда. Дачачылар да бар. Жәй коне, башка авыллардагы тосле, кунакка туганнары кайта. Туган як тарта шул. Потьмачылар бик тату яшәгәнгә, барысынын хәл-әхвәлән, бер-берсенен тормыш нечкәлекләрен беләләр. Алар шатлыкта да, кайгыда да бергәләр. Авыл халкы берсенә берсе кирәк. Биредә хәтта бергә кушылып жыйган акчага туган коннәренә бvләк алулар да традициягә кергән. Ә бәйрәм vткәрсәләр - барысы да кунакка чакырыла; бергәләп кvнел ачалар.      Быел Потьмалыларга «Сабантуй" vткәрv зур вакыгага әйләнде. Аны авыл эшмәкәре Наиль Алимбек улы Еналеев оештырган. Ул берәр эш башлый икән, һәрвакыт ин югары дәрәжәдә оештыра. Наиль Алимбекович менә нәрсә ди:

- Якташларыма ихтирам йозеннән бәйрәм vткәрергә дип vткән ел ук уйлаган идем. Олылар конендә, бvләкләр тапшыру вакытында, авылдашларыма “Сабантуй” бәйрәмен vткәрәм дидем. Әйткән сvз – каккан казык, шулай тәвәккәлләдем.  Чын-чынлап әйткәндә, озак әзерлек эшләре белән йорергә туры килде. Бәйрәмгә кирәк-яраклар заказ белән алдырттым, бизәv-оформлениесе белән Саранск белгечләре шогыльләнде. Мәдәни программасын тормышка ашыру максаты белән башкалабыз драмтеатр артистларын, Ләмберә vзэшчән коллективын, Латышовка һәм Большая Полянадан артистларын татар, рус, мукшы һәм башка милләт жырларын, биюләрен башкарырга чакырдым. Алдан ук менюны да билгеләдем, савыт-саба, аш-су якларын да кайгырттым... Бәйрәмнен спорт олешен дә булдырдым. Чараны тамаша кылганнан сон, авылдашларымны милли ашлар (плау, камырдан пешкән тәмлушкалар) белән тулган остәлләр котеп торды. Һәрбер кешене, ата-бабалардан калган кунакчыллык традицияләрен дәвам итеп, мулдан кыстарга телədем. Бу чара белән районыбызда якташларыбызга шундый хәйрия (благотворительный) бәйрәмнәр vткәрv традициясен ачып жибәрергә телим.

Насакан Потьма “Сабантуе”нда катнашучылар әйтvенчә, бәйрәм ойдәге тосле кызыклы һәм жылы vтте.

- Карангы тонгә кадәр татар жырлары янгырады, шуна кvнелне рәхәтлек хисе биләде. “Сабантуй” авылнын һәрбер йортына кереп, һәрбер капка алдында булды һәм һәрбер катнашучыны шатландырды. Кунаклар, якташларыбыз тагы һәм тагы шундый

Сабантуйлар vтәсенә ышанып таралыштылар. Наиль Алимбек улы Еналеев vткәргән бәйрәм vзендә шатлык, киләчәккә ышаныч тудырды, тормышны тагы да матур итv теләге уятты. Ул доньянын торле почмакларына сибелгән якташларыбызны, кунакларны жыеп авыл хәлләре турында уртага салып сойләште, кунак итте, кvнелләрен ачты. Бәйрәм матур салют белән тәмамланды, - дип сойләде бу чарада катнашкан Светлана Мухаметжан кызы Асаинова.
Тагы бер бәйрәм. Шул ук авылда гомер иткән Рәхимә апа Невлютовага 90 яшь тулды. Россия Президенты В.В. Путиннан олы Юбилее б



елән котлау хатын Рәхимә Абдулла кызы алган. Аны котлап авылы халкы, район администрациясе вәкилләре, соцзащита һәм ветераннар оешмаларыннан килгәннәр. Рәхимә Абдулла кызы Невлютова авыр балачак vткәргән кеше. Язмыш аны ныклыкка бер генә тапкыр сынамаган, ул әле яши һәм булдыра алганча кирәк-ярагын башкара. Истәлекләр. 1937нче елда әтисен кулга алулары бvген дә ап-ачык хәтерендә. Шул вакыт ана бит 11 яшь кенә була. Кайгы ялгыз йорми, диләр бездә: озакламый Боек Ватан сугышы башлана. Тормыш итәргә тагы да кыенлаша. Биш баланы әнисе берvзе генә тәрбияләп vстерә. Шуна Рәхимә дә иртә олыгая, чонки әнисенә ярдәм итәр очен колхозга эшкә йори башлый. Бетмәс-токәнмәс авыр хезмәт ойдә дә, бакчада да, кырда да; шушы гаиләдәге кечкенә балалар турында кайгырту, - боларнын барысы да анын тормышында зур роль уйнаган. Сура рубежына окоплар казырга да туры килә яшvсмер кызга, хәтта торфоразработкаларда да. Мостәкыйль кыз булып vсеп житкәч тә, ул эшсез утыра алмаган, беркемгә дә ярдәм кvрсәтvдән баш тартмаган һәм шуна да авылдашларынын хормәтен казанган. Белемле дә булырга тели ул. Инсар шәһәре агрономнар әзерли торган техникумга укырга керә, әмма финанслар ягы коры булганга, укып бетерә алмый - ташлый.
Рәхимә апанын бәхетле коннәре 1945 елда башлана. Беренчедән, Боек Ватан сугышы бетә. Олы мәхәббәт белән фронтавик Зариф абый Невлютовка кияvгә чыга. Озак еллар ул урман краучы булып хезмәт итә, ә Рәхимә апа - колхозда яшелчә vстерә. Шулай ирле-хатынлы дvрт бала тәрбияләп vстерәләр.
Бәхетне кайгы сагалап йори, диләр. Шулай була да. Гомер горләп барганда, фронтта

алган яраларыннан Зариф абый бакыйлыкка кvчә. Рәхимә апанын шатлыгы һәм юанычы булып балалары һәм оныклары, оныкчыкларында кала. Алар бер дә әниләрен һәм әбәйләрен онытмыйлар; Насакан Потьма авылына килеп-китеп йориләр. Оныклары бvген дә соекле әбиләренен пешергән авыл пәрәмәчләре һәм бәлешләренен тәме тел очларында тора дип искә алалар. Хәзер Рәхимә апа Невлютова кече кызы кадер-хөрмәтендә Кадошкинода яши. Хезмәт һәм тыл ветеранынын 7 оныгы һәм 9 оныкчыгы- правнугы шатландырып vсәләр. Шулай ана картлык та шатлык.
Менә шундый ике олы бәйрәм кечкенә Насакан Потьма авылында vтә.

**Наилә Насырова**